| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь 2019 ел № 5575

«2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны шәһәр бюджетының «Мәгариф» бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 2020 елга – 5 947 653,88 мең сум, 2021 елга – 5 936 797,51 мең сум, 2022 елга – 5 936 797,51 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 30 октябрендәге
5575 нче карарына
кушымта

«2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре Уставы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, муниципаль белем бирү учреждениеләре |
| Программаның максаты | Кеше потенциалын формалаштыру һәм шәһәрне социаль яңарту нигезе буларак, Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү өчен оптималь шартлар тудыру һәм барлык дәрәҗәләрдә сыйфатлы белем бирүне тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | 1) мәктәптә уңышлы укыту нигезе буларак, балаларны тиешенчә физик һәм психологик яктан үстерү өчен мәктәпкәчә белем бирүнең кирәкле шартларын тәэмин итү;<br>2) гомуми белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә белем бирү программаларының күчә баруы нигезендә белем бирү сыйфатын тәэмин итү өчен шартлар тудыру;<br>3) белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә белем бирү процессына психологик ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәле системасын булдыру;<br>4) шәһәрдә интеллектуаль һәм иҗади эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне ачыклау, үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтүнең бердәм системасын булдыру өчен уңайлы шартлар тудыруны тәэмин итү;<br>5) шәхеснең иҗади индивидуальлеген үстерү һәм социализацияләү өчен шартларны тәэмин итү;<br>6) белем бирү процессын укыту-методик яктан тәэмин итү, уку-укыту процессын оештыруга яңа формалар һәм технологияләр кертүне активлаштыру;<br>7) тармакның компетентлы, югары квалификацияле белгечләргә ихтыяҗын тәэмин итү |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2020-2022 еллар |

<table>
<tr><td rowspan="6">Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2020 ел (мең сум)</td><td>2021 ел (мең сум)</td><td>2022 ел (мең сум)</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>5947653,88</td><td>5936797,51</td><td>5936797,51</td><td>17821248,9</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>5947653,88</td><td>5936797,51</td><td>5936797,51</td><td>17821248,9</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Искәрмә: финанслау күләме прогноз характерына ия һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Программаны тормышка ашыруның йомгаклау нәтиҗәләре:<br>1) куллануучыларның белем бирү сыйфатынан канәгатьлеген арттыру;<br>2) вакыт таләпләре нигезендә укучыларның яңа белем бирү нәтиҗәләрен; укытучының яңа статусы һәм һөнәри осталыгы, белем бирүнең яңа мохитен формалаштыру нигезендә белем бирү сыйфатын тәэмин итү – укучыларның барлык категорияләре ихтыяҗларын исәпкә алып;<br>3) шәһәрнең мәгариф системасында социаль партнерлыкны һәм иҗтимагый-дәүләт идарәсен киңәйтү.<br>Программаны тормышка ашыруның икътисадый нәтиҗәләре:<br>1) хезмәт базарын инновацион икътисадка күчү шартларында эшләргә сәләтле квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү;<br>2) җан башына финанслау куллану һәм белем бирү учреждениеләренең проект куәтен тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="5">Программаның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Башкарма комитетының мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа методы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Шәһәрнең мәгариф системасын үстерү төп стратегик максат нигезендә гамәлгә ашырыла – кеше потенциалын формалаштыру һәм шәһәрне социаль яңарту нигезе буларак, Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү өчен оптималь шартлар тудыру һәм барлык дәрәҗәләрдә сыйфатлы белем бирүне тәэмин итү, шәһәрнең белем бирү оешмаларында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр өчен куркынычсыз мохит булдыру. Нәтиҗәдә, шәһәрдә мәгариф системасы белән идарә итү структурасы булдырылды, ул максатчан программа алымы нигезендә аның тотрыклы үсешен тәэмин итә.

«Мәгариф» өстенлекле илкүләм проектын модернизацияләү һәм хәл итү барышында түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелде:

1) уку курсларының темаларын һәм исемлеген киңәйтү, социаль интеграцияләнгән модульләрне кертү, белем бирү эчтәлеген интеграцияләү чаралары буларак тикшерену һәм проект эшчәнлеген киң куллану ярдәмендә белем бирү эчтәлеген яңарту процессы тизләтелде;

2) үз мотивацияләре һәм җаваплылыклары, мультимедиа курслары, мульти - һәм видеотекалар, электрон ресурслар һәм белем бирү порталлары рәвешендә мәгълүмати һәм компьютер технологияләренән файдалану нигезендә балаларны укытуны тәэмин итә торган белем бирү процессын оештыруның яңа формаларын һәм технологияләрен кертү активлашты;

3) белем бирүнең актив формалары – конференцияләр, слетлар, уку уеннары, проектлар, фәнни җәмгыять фестивальләре белән белем бирү баетылды;

4) белем бирү сыйфаты белән идарә итү өчен шәһәр дәрәҗәсендә мониторинг системасын эшләү алып барыла;

5) кулланучыларның ихтыяҗларын һәм өметләрен максималь рәвештә тормышка ашыру максатында дәүләт-иҗтимагый идарә формалары (күзәтү, попечительлек советлары, мәктәпләр советлары) киңәйтелә, шәһәр ата-аналар комитеты, Балалар шәһәр Думасы, Яшь белгечләр советы формалаштырыла;

6) башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары үзгәртеп корылды, мәгариф кластерлары булдырылды.

Шәһәрнең белем бирү оешмаларын мәгълүматлаштыруның яңа сыйфатына ирешелде: федераль бюджет хисабына шәһәрнең барлык мәгариф оешмалары югары тизлекле Интернет челтәренә тоташтырылды.

Шәһәрдә педагогик хезмәт абруен күтәрү буенча системалы эш гамәлгә ашырыла (конкурслар үткәрелә).

Укучыларның һәм тәрбияләнүчеләрнең комплекслы куркынычсызлыгы өчен шартлар тудыру максатында, барлык учреждениеләр дә тышкы видеокүзәтү белән тәэмин ителде. Барлык белем бирү оешмалары автоматлаштырылган янгын сигнализациясе системасы белән җиһазландырылды.

Шуның белән бергә, түбәндәге юнәлешләр буенча кайбер проблемаларны хәл итәргә кирәк булачак:

1) белем бирү эчтәлеген федераль дәүләт белем бирү стандарты (алга таба – ФДББС) белән килешенү;

2) белем бирү оешмаларында компетентлы, системалы эшчәнлек алымы нигезендә яңа белем бирү мохите булдыру;

3) укучыларның яңа белем нәтиҗәләрен формалаштыру өчен шартлар тудыру максатында тәрбия, өстәмә белем бирү системасын – төп компетентлык һәм социализация системасын камилләштерү;

4) педагогик кадрларны әзерләү һәм яңадан әзерләү системасын үзгәртеп кору;

5) ФДББС кертү нигезендә белем бирү сыйфатын бәяләүнең шәһәр системасын үстерү;

6) мәгарифне үстерү программасын тормышка ашыру шартларында шәһәрнең мәгариф системасын фәнни, фәнни-методик, психологик, мәгълүмати тәэмин итү һәм ярдәм күрсәтү.

Программаны эшләү сәбәпләрен анализлау.

Россия мәгарифен модернизацияләү концепциясе идеяләрен тормышка ашыру кысаларында, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыру өчен мәгариф системасын үстерү программасын эшләү зарурлыгы барлыкка килде:

1) белем бирү сыйфатын күтәрү;

2) профиль алды һәм профильле белем бирүне тормышка ашыру;

3) сәләтле балалар белән эш оештыру;

4) сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен ФДББС кертү;

5) инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

6) югары квалификацияле педагогик кадрлар әзерләү.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максаты – кеше потенциалын формалаштыру һәм шәһәрне социаль яңарту нигезе буларак, Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү өчен оптималь шартлар тудыру һәм барлык дәрәҗәләрдә сыйфатлы белем бирүне тәэмин итү.

Юнәлешләр буенча бурычлар:

1) мәктәпкәчә белем бирүдә – мәктәптә уңышлы укыту нигезе буларак, балаларны тиешенчә физик һәм психологик яктан үстерү өчен мәктәпкәчә белем бирүнең кирәкле шартларын тәэмин итү;

2) гомуми белем бирүдә – гомуми белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә белем бирү программаларының көчә баруы нигезендә белем бирү сыйфатын тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

3) мәгарифне психологик тәэмин итүдә – психологик ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәле системасын булдыру;

4) сәләтле балалар һәм яшьләр белән эшләүдә – шәһәрдә интеллектуаль һәм иҗади эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне ачыклау, үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтүнең бердәм системасын булдыру өчен уңайлы шартлар тәэмин итү;

5) балаларга һәм яшьләргә өстәмә белем бирүдә – шәхеснең иҗади индивидуальлеген үстерү һәм социализацияләү өчен шартларны тәэмин итү;

6) укыту-методик ярдәм күрсәтү – белем бирү процессына укыту-методик ярдәм күрсәтү, уку-укыту процессын оештыруга яңа формалар һәм технологияләр кертүне активлаштыру;

7) кадрлар сәясәтендә – тармакның компетентлы, югары квалификацияле белгечләргә ихтыяҗын тәэмин итү.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

| Т/с | Этапның исеме | Тормышка ашыру чоры |
|---|---|---|
| 1 | Программаны тормышка ашыру | 2020-2022 еллар |
| 2 | Йомгак ясау | 2022 елның 4 кварталы |

## 5 бүлек. Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары

| Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2020 ел (мең сум) | 2021 ел (мең сум) | 2022 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |
| Муниципаль бюджет | 5947653,88 | 5936797,51 | 5936797,51 | 17821248,9 |

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмнары

Программаны тормышка ашыру барышында муниципаль заказчы-координатор (Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе) төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны тормышка ашыру барышын һәм турыдан-

туры башкаручыларның акчаларын нәтиҗәле файдалануны контрольдә тота. Программа чараларын тормышка ашыру катгый рәвештә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль программаларны тормышка ашыруга агымдагы мониторинг үткәрү өчен, Программа координаторы Башкарма комитетның финанс идарәсенә һәм Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә ел саен, хисап чорыннан соң килгән елның 1 февраленә кадәр, Программаны тормышка ашыру барышы турында хисап, нәтиҗәлелеккә һәм тормышка ашыру нәтиҗәлелегенә бәяләмә җибәрә.

## 7 бүлек. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү Программасын тормышка ашыру нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) кулланучыларның белем бирү сыйфатыннан канәгатьлеген арттыру;

2) вакыт таләпләре нигезендә укучыларның яңа белем нәтиҗәләрен; укытучының яңа статусы һәм һөнәри осталыгы, белем бирүнең яңа мохитен формалаштыру нигезендә белем бирү сыйфатын тәэмин итү – укучыларның барлык категорияләре ихтыяҗларын исәпкә алып;

3) шәһәрнең мәгариф системасында социаль партнерлыкны һәм иҗтимагый-дәүләт идарәсен киңәйтү.

Программаны тормышка ашыруның икътисадый нәтиҗәләре:

1) хезмәт базарын инновацион икътисадка күчү шартларында эшләргә сәләтле квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү;

2) җан башына финанслау куллану һәм белем бирү учреждениеләренең проект куәтен тәэмин итү.

## 8 бүлек. Программа нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

| Т/с | Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы | Мәгълүмат чыганаклары |
|---|---|---|---|
| 1. | Укучыларны гомуми белем бирүнең ФДББС җәлеп итү (%) | I=A/B*100%, монда<br>А – ФДББС буенча гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалар саны<br>В – мәктәп яшендәге балалар саны | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы Форма РИК - 76 |
| 2. | Укучыларның өлгереше | I=A/B*100%, монда<br>А – канәгатьләнерлек нәтиҗәләре булган 2-11 нче сыйныфтагы балалар саны;<br>В – гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы 2-11 нче сыйныфтагы балалар саны | Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 3. | Укучыларның белем сыйфаты | I=A/B*100%, монда<br>А – «бик яхшы» һәм «яхшы» билгеләренә укучы 2-11 нче сыйныфтагы балалар саны;<br>В – гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы 2-11 нче сыйныфтагы балалар саны | Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 4. | Күрсәтелә торган хезмәт шартларыннан һәм сыйфатыннан канәгать булган ата-аналар өлеше | I=A/B*100%, монда<br>А – күрсәтелә торган хезмәт сыйфатыннан канәгать булган ата-аналар саны;<br>В – гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларның ата-аналары саны | Гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5. | Башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын үзләштерүне йомгак бәяләү нәтиҗәләре буенча үз белемнәрен раслаган укучылар өлеше | I=A/B*100%, монда<br>A - Башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын өйрәнүне йомгак бәяләү нәтиҗәләре буенча үз белемнәрен раслаган укучылар саны;<br>B – башлангыч мәктәптә укучылар саны | Гомуми белем бирү учреждениеләре житәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 6. | Төп гомуми белем бирүнең гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестацияләре нәтиҗәләре буенча үз белемнәрен раслаган укучылар өлеше | I=A/B*100%, монда<br>A – дәүләт йомгаклау аттестациясен уңышлы үткән 9 нчы чыгарылыш сыйныф укучылары саны;<br>B – имтиханнар тапшырган 9 нчы чыгарылыш сыйныф укучылары саны | Гомуми белем бирү учреждениеләре житәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 7. | Урта гомуми белем бирүнең гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестацияләре нәтиҗәләре буенча үз белемнәрен раслаган укучылар өлеше | I=A/B*100%, монда<br>A – рус теле һәм математика буенча имтиханнарны уңышлы тапшырган 11 нче чыгарылыш сыйныф укучылары саны;<br>B – рус теле һәм математика буенча имтихан тапшырган 11 нче чыгарылыш сыйныф укучылары саны | Гомуми белем бирү учреждениеләре житәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 8. | Төп гомуми белем бирүнең гомуми белем бирү программасын үзләштергән чыгарылыш укучыларының чагыштырма авырлыгы | I=A/B*100%, монда<br>A – дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буенча аттестат алган 9 нчы чыгарылыш сыйныф укучылары саны;<br>B – 9 нчы чыгарылыш сыйныф укучылары саны | Гомуми белем бирү учреждениеләре житәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 9. | Урта гомуми белем бирүнең гомуми белем бирү программасын үзләштергән чыгарылыш укучыларының чагыштырма авырлыгы | I=A/B*100%, монда<br>A – дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буенча аттестат алган 11 нче чыгарылыш сыйныф укучылары саны;<br>B – 11 нче чыгарылыш сыйныф укучылары саны | Гомуми белем бирү учреждениеләре житәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 10. | Белем бирү оешмаларының федераль һәм региональ исемлек нигезендә укыту-методик әсбаплар һәм жиһазлар белән тәэмин ителеше (%) | I=A/B*100%, монда<br>A – гомуми белем бирү оешмаларында белем бирү процессы өчен кирәкле укыту-күрсәтмә һәм спорт жиһазлары һәм әсбаплар булу;<br>B – ФДББС нигезендә белем бирү процессы өчен кирәкле укыту-күрсәтмә һәм спорт жиһазлары һәм әсбаплары | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы Форма 73 |
| 11. | Шәхси медик-социаль һәм психологик-педагогик ярдәм белән тәэмин ителгән аерым белем алу ихтыяжлары булган балалар өлеше | I=A/B*100%, монда<br>A – психологик-медицина-социаль ярдәмнән файдаланган балалар саны;<br>B – психологик-медицина-социаль ярдәмгә мохтаж балалар саны | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар турында мәгълүматлар базасы |
| 12. | Төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, фестивальләрдә, фәнни һәм ижади конференцияләрдә катнашучы белем бирү оешмаларында укучылар өлеше (%) | I=A/B*100%, монда<br>A – конкурсларда катнашучы гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны;<br>B – шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы Форма ОО-1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | Мәктәп укучыларының бөтенроссия олимпиадасының региональ этабында җиңүчеләр һәм призерлар өлеше (%) | I=A/B*100%, монда<br>A – Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының региональ этабында җиңүчеләр һәм призерлар саны;<br>B – фестивальләрдә һәм конкурсларда катнашкан укучылар саны | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы Форма ОО-1 |
| 14. | Төрле дәрәҗәдәге фестиваль һәм конкурсларда җиңүчеләр һәм призерлар өлеше (%) | I=A/B*100%, монда<br>A – фестиваль һәм конкурсларда җиңүчеләр һәм призерлар саны;<br>B – фестиваль һәм конкурсларда катнашкан укучылар саны | Өстәмә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 15. | Укучыларны балаларга һәм яшьләргә өстәмә белем бирү программалары белән тәэмин итү | I=A/B*100%, монда<br>A – өстәмә белем бирү учреждениеләренә йөрүче гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны<br>B – шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны | Өстәмә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә муниципаль йөкләмәләр |
| 16. | Һөнәри осталыкны арттыру буенча конкурсларда, конференцияләрдә катнашучы педагоглар өлеше | I=A/B*100%, монда<br>A – конкурсларда һәм конференцияләрдә катнашучы педагоглар саны;<br>B – шәһәрнең белем бирү оешмаларында эшләүче педагоглар саны | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы Форма 73 |
| 17. | «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (алга таба – АМС) аша 2,5 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин итү (%) | I=A/B*100%, монда<br>A – балалар бакчасына кабул ителгән балалар саны;<br>B – «Электрон балалар бакчасы» АМС чиратта торучы балаларның гомуми саны | «Электрон балалар бакчасы» АМС |
| 18. | 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урыннар белән тәэмин итү (%) | I=A/B*100%, монда<br>A – мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә урын алган 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балалар саны;<br>B – «Электрон балалар бакчасы» АМС чиратта торучы 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балаларның гомуми саны | «Электрон балалар бакчасы» АМС |
| 19. | Квалификация категорияләре булган педагоглар өлеше | I=A/B*100%, монда<br>A – квалификация категорияләре булган педагоглар саны;<br>B – педагогларның гомуми саны | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы Форма 73 |
| 20. | Фәнни-эксперименталь эшчәнлектә, инновацион проектларда катнашучы педагоглар өлеше (%) | I=A/B*100%, монда<br>A – фәнни-эксперименталь эшчәнлектә, инновацион проектларда катнашучы педагоглар саны;<br>B – шәһәрнең белем бирү оешмаларында эшләүче педагоглар саны | Башкарма комитетның «Төп гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү» 2012 елның 30 июлендәге 4045 нче карары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21. | Мәктәп укучыларын ташламалы кайнар аш белән тәэмин итү (%) | I=A/B*100%, монда<br>А – кайнар аш белән тәэмин ителә торган күп балалы гаиләләрдәге балалар саны;<br>В – 4 һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрнең мәктәп яшендәге балалар саны | Башкарма комитетның «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру чаралары турында» 2018 елның 25 декабрендәге 7767 нче карары |
| 22. | Инклюзив һәм адаптацияләнгән белем бирүне үстерү юлы белән сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны (аутистларны) гомуми белем белән тәэмин итү (%) | I=A/B*100%, монда<br>А – аутистик спектры бозылган, махсус шартлар таләп итә торган балалар саны;<br>В – аутистик спектры бозылган мәктәп яшендәге балалар саны | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы |
| 23. | Инвалидлар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле (алга таба – СЯМЧ) кешеләр өчен бинада техник күчеш чаралары белән тәэмин ителгән гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше | I=A/B*100%, монда<br>А – инвалидлар һәм СЯМЧ кешеләр өчен бинада техник күчеш чаралары белән тәэмин ителгән белем бирү учреждениеләре саны;<br>В – белем бирү учреждениеләре саны | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы |
| 24. | Мәктәпкәчә белем бирүнең яңа формаларын да кертеп, инклюзив, интегратив һәм махсус белем бирүне үстерү юлы белән, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны мәктәпкәчә белем белән тәэмин итү (%) | I=A/B*100%, монда<br>А – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле, махсус белем бирү формаларын таләп итүче мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны;<br>В – мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны | Уку елы йомгаклары буенча Россия Федерациясенең статистика хисаплылыгы |

9 бүлек. Муниципаль программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | |
| | | | | | | Финанслау чыганагы – муниципаль бюджет | | | |
| Максатның исеме: кеше потенциалын формалаштыру һәм шәһәрне социаль яңарту нигезе буларак, Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү өчен оптималь шартлар тудыру һәм барлык дәрәҗәләрдә сыйфатлы белем бирүне тәэмин итү.<br>Ярдәмче программа: Мәктәпкәчә белем бирү<br>Бурычның исеме: мәктәптә уңышлы укыту нигезе буларак, балаларны тиешенчә физик һәм психологик яктан үстерү өчен мәктәпкәчә белем бирүнең кирәкле шартларын тәэмин итү. | | | | | | | | | |
| Һәркем ала алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем бирүне тәэмин итү | - «Электрон балалар бакчасы» АМС аша 2,5 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем бирү оешмаларда урыннар белән тәэмин итү;» (%)<br>- 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәрге балаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урыннар белән тәэмин итү (%) | 100<br><br>40,2 | 100<br><br>52,5 | 100<br><br>78,0 | 100<br><br>100 | 2457283,21 | 2450768,05 | 2450768,05 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге |
| Инклюзив белем бирүне оештыру | Мәктәпкәчә белем бирүнең яңа формаларын кертеп, инклюзив, интегратив һәм махсус белем бирүне үстерү юлы белән 3 яшьтән башлап инвалид балаларны һәм | 89 | 90 | 91 | 92 | 26232,7 | 26232,7 | 26232,7 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны мәктәпкәчә белем алуга җәлеп итү (%) | | | | | | | | |
| Ярдәмче программа: Гомуми белем бирү<br>Бурычның исеме: гомуми белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә белем бирү программаларының күчә баруы нигезендә белем бирү сыйфатын тәэмин итү өчен шартлар тудыру. | | | | | | | | | |
| Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең ФДББС тормышка ашыру | - укучыларны гомуми белем бирү ФДББС җәлеп итү (%);<br>- укучыларның өлгереше;<br>- укучыларның белем сыйфаты;<br>- күрсәтелә торган хезмәт шартларыннан һәм сыйфатыннан канәгать булган ата-аналар өлеше;<br>- башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын үзләштерүне йомгак бәяләү нәтиҗәләре буенча үз белемнәрен раслаган укучылар өлеше;<br>- төп гомуми белем бирүнең гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестацияләре нәтиҗәләре буенча үз белемнәрен раслаган укучылар өлеше;<br>- урта гомуми белем | 100<br>100<br>55,3<br>100<br>100<br>100<br>100 | 100<br>100<br>56,0<br>100<br>100<br>100<br>100 | 100<br>100<br>57,0<br>100<br>100<br>100<br>100 | 100<br>100<br>58,0<br>100<br>100<br>100<br>100 | 2755691,13 | 2755093,33 | 2755093,33 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең гомуми белем бирү бүлеге |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бирүнең гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестацияләре нәтиҗәләре буенча үз белемнәрен раслаган укучылар өлеше;<br>- төп гомуми белем бирүнең гомуми белем бирү программасын үзләштергән чыгарылыш укучыларының чагыштырма авырлыгы;<br>- урта гомуми белем бирүнең гомуми белем бирү программасын үзләштергән чыгарылыш укучыларының чагыштырма авырлыгы;<br>- мәктәп укучыларын ташламалы кайнар аш белән тәэмин итү (%) | 100<br>100 | 100<br>100<br>3,0 | 100<br>100<br>3,5 | 100<br>100<br>4,0 | | | |
| Гомуми белем бирү учреждениеләрендә инклюзив һәм адаптацияләнгән белем бирүне оештыру | Инклюзив һәм адаптацияләнгән белем бирүне үстерү юлы белән СЯМЧ балаларны (аутистларны) гомуми белем алуга җәлеп итү (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | 2405,5 | 2405,5 | 2405,5 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең гомуми белем бирү бүлеге «85 нче психологик-медицина-социаль ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | «3 нче урта гомуми белем бирү учреждениесе» МБГББУ<br>«53 нче урта гомуми белем бирү учреждениесе» МБГББУ |
| СЯМЧ балаларга һәм инвалид балаларга белем бирүне тәэмин итү | Инвалидлар һәм СЯМЧ кешеләр өчен бинада техник күчеш чаралары белән тәэмин ителгән гомуми белем бирү учреждениеләре өлеше | 6,25 | 6,5 | 6,75 | 6,75 | 0 | 0 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең гомуми белем бирү бүлеге |
| 9, 11 нче сыйныфларда бердәм дәүлә һәм төп дәүләт имтиханы формасында дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм үткәрү өчен шартлар тудыру (имтиханнарны кабул итү пунктларын җиһазландыру) | 9, 11 (12) нче сыйныфларда имтиханнар үткәрү пунктлары буларак җиһазландырылган белем бирү оешмалары саны | 24 | 24 | 25 | 26 | 0 | 0 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең гомуми белем бирү бүлеге<br><br>Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Бурычның исеме: белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә белем бирү процессына психологик ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәле системасын булдыру. | | | | | | | | | |
| Мәҗбүри социаль изоляция шартларында калган мәктәп яшендәге балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү, СЯМЧ балаларны укыту өчен шартлар тудыру | Индивидуаль медицина-социаль һәм психологик-педагогик ярдәм белән тәэмин ителгән аерым белем бирү ихтыяҗлары булган балалар өлеше (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | 8074,02 | 8132,38 | 8132,38 | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе<br><br>«85 нче психологик-медицина-социаль ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе |
| Бурычның исеме: шәһәрдә интеллектуаль һәм иҗади эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә сәләтле балаларны һәм талантлы яшьләрне ачыклау, үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтүнең бердәм системасын булдыру өчен уңайлы шартлар тудыруны тәэмин итү. | | | | | | | | | |
| Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасында катнашу | Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының региональ этабында җиңүчеләр һәм призерлар өлеше (%) | 49 | 49 | 49 | 49 | 0 | 0 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең гомуми белем бирү бүлеге<br><br>Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары |
| Лицей-интернатларда балалар өчен белем һәм тәрбия бирү программасын тормышка ашыру | Белем бирү оешмаларының Федераль һәм региональ исемлек нигезендә укыту-методик әсбаплар һәм җиһазлар белән тәэмин ителеше | 98 | 98 | 98,5 | 99 | 90125,47 | 89393,50 | 89393,50 | «79 нчы лицей-интернат» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (%) | | | | | | | | «Г. Акыш исемендәге 84 нче лицей-интернат» муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе |
| - «Һөнәрләр дөньясы»;<br>- «Вожатыйлар осталыгы»;<br>- «Ел укучысы»;<br>- «Иң яхшы постта торучы»;<br>- «Хокук бозуларны профилактикалау буенча иң яхшы мәктәп отряды»;<br>- «Иң яхшы тимурчылар отряды» шәһәр конкурсларын оештыру һәм үткәрү | Төрле дәрәҗәдәге конкурсларда, фестивальләрдә, фәнни һәм иҗади конференцияләрдә катнашучы белем бирү оешмаларында укучылар өлеше (%) | 22 | 22 | 23 | 23 | 0 | 0 | 0 | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе<br><br>Муниципаль гомуми белем бирү оешмалары |
| Ярдәмче программа: Өстәмә белем бирү<br>Бурычның исеме: шәхеснең иҗади индивидуальлеген үстерү һәм социализацияләү өчен шартлар тудыру. | | | | | | | | | |
| Сәнгать-эстетика юнәлешендәге оешмалар тарафыннан өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтү | Төрле дәрәҗәдәге фестиваль һәм конкурсларда җиңүчеләр һәм призерлар өлеше (%) | 22 | 23 | 24 | 24,5 | 412780,16 | 411657,45 | 411657,45 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең тәрбия һәм өстәмә белем бирү бүлекчәсе |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | Сәнгать-эстетика юнәлешендәге муниципаль өстәмә белем бирү учреждение ләре |
| Өстәмә белем бирү учреждениеләре тарафыннан төрле юнәлештәге программаларны тормышка ашыру | Укучыларны балаларга һәм яшьләргә өстәмә белем бирү программаларына җәлеп итү (%) | 100 | 100 | 100 | 100 | 183657,23 | 181319,84 | 181319,84 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең тәрбия һәм өстәмә белем бирү бүлекчәсе<br><br>Күп профильле юнәлештәге муниципаль өстәмә белем бирү учреждение ләре |
| Укыту-методик ярдәм<br>Бурычның исеме: белем бирү процессын укыту-методик яктан тәэмин итү, уку-укыту процессын оештыруга яңа формалар һәм технологияләр кертүне активлаштыру. | | | | | | | | | |
| Шәһәрнең белем бирү оешмаларында фәнни-консультация эшен, инновацияләр, фәнни тикшеренү методлары буенча семинарлар оештыру | Фәнни-эксперимент эшчәнлегендә, инновацион проектларда катнашучы педагоглар өлеше (%) | 38 | 38 | 39 | 39 | 11404,46 | 11794,76 | 11794,76 | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе<br><br>«Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тармакны кадрлар белән тәэмин итү<br>Бурычның исеме: Тармакның компетентлы, югары квалификацияле белгечләргә ихтыяҗын тәэмин итү. | | | | | | | | | |
| Педагогларның квалификациясен күтәрү эшен оештыру | Квалификация категорияләре булган педагоглар өлеше (%) | 70,2 | 72 | 74 | 76 | 0 | 0 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең оештыру-педагогик тәэмин итү һәм социаль яклау бүлеге |
| Педагоглар арасында<br>- «Ел укытучысы»;<br>- «Ел педагог-психологы»;<br>- «Ел сыйныф җитәкчесе»;<br>- «Өстәмә белем бирү педагогы» конкурслары оештыру һәм үткәрү | Һөнәри осталыкны күтәрү буенча конкурсларда, конференцияләрдә катнашучы педагоглар өлеше (%) | 33 | 33 | 34 | 35 | 0 | 0 | 0 | Башкарма комитет мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең оештыру-педагогик тәэмин итү һәм социаль яклау бүлеге |

10 бүлек. Программаны финанс ягыннан тәэмин итү чыганаклары һәм күләме

Күрсәтелгән бүленеш прогноз характерына ия һәм Яр Чаллы шәһәре бюджеты проектларын формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә ел саен төгәллек кертелергә тиеш.

| Программаның бүлекләре | Еллар буенча финанс ягыннан тәэмин итү | | |
|---|---|---|---|
| | Финанслау чыганагы – муниципаль бюджет (мең сум) | | |
| | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Гомуми белем бирү системасы | 2758096,63 | 2757498,83 | 2757498,83 |
| Интернатлар системасы | 90125,47 | 89393,50 | 89393,50 |
| Күп профильле оешмаларда өстәмә белем бирү системасы | 183657,23 | 181319,84 | 181319,84 |
| Сәнгать-эстетика юнәлешендәге өстәмә белем бирү системалары | 412780,16 | 411657,45 | 411657,45 |
| Укыту-методик ярдәм күрсәтү системалары | 11404,46 | 11794,76 | 11794,76 |
| Психологик-медицина-педагогик ярдәм күрсәтү системасы | 8074,02 | 8132,38 | 8132,38 |
| Мәктәпкәчә белем бирү системалары | 2483515,91 | 2477000,75 | 2477000,75 |
| барлыгы: | 5947653,88 | 5936797,51 | 5936797,51 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — Н.И. Галиева

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ